


Ел саен Ләмберә районынын «Алмаз» мәдәни-спорт vзәге кечкенә авыллар һәм Ләмберә урамнары бәйрәмнәре vткәреп килә. Бу матур гадәт халыкка бик тә ошый. Язасы бәйрәмнен оештыручысы һәм алып баручысы хормәтле Альфия Асым кызы Максимова иде.
Шулай, 9 сентябрьдә Энергетик-лар урамы бәйрәме vткән. Коннен янгырлы булуына карамастан, бу чарада Ләмберә кешеләре һәм кунаклары рәхәтләнеп катнашканнар һәм ял иткәннәр. Кон программасында урамда яшәгән олыларны, балаларны, унган хужабикәләрне һәм ирләрне – бер сvз белән әйткәндә, хормәткә лаек Энергетиклар урамында яшәvче кешеләрне барлаганнар.



Тарихка тукталыйк. 1990нчы елны Ләмберәнен «Победа» колхозы vзенен эшчеләренә 10ар сотый жирне йортлар тозv очен бvлеп бирә. Бу урамда беренчеләрдән буларак Альберт Мукаддяс улы белән Анна Степановна Исякаевлар йорт тозеп яши башлыйлар. Икенчеләре – Раис Хосәен улы белән Римма Аббяс кызы Куряевлар; тагы ике йортны «Развитие села» фонды ярдәме белән тозиләр. Ә урамга исемне электр подстанциясе янында урнашканга Энергетиклар дип кушалар.
Икенчеләрдән йорт тозегән Раис Хосәен улы белән Римма Аббяс кызы Куряевлар йорты бvген «Дом образцового содержания» исеменә лаек. Аларны бәйрәмдә котлап бvләкләр тапшырдылар. Йорт хужасы – бул-дыклы пенсионер, бар эшне дә жиренә житкереп башкаручы запастагы офицер, 500 сәгать очкан һәм 5 тапкыр парашюттан сикергән очучы, 25 ел сатуда хезмәт иткән, кадерле ике бала әтисе, соекле 4 онык бабакае булган Раис Хосәен улы Куряев. Ул кvргәзмә оештырганда да аерым сәләт һәм осталык белән оештырган.
Энергетиклар урамында яшәгән ин олылар арасында Шахидулла Мавлют улы Сюбаев (1939 елда туган), 86 яшьлек Серафима Васильевна Захарова, кызында яшәгән 91 яшьлек Фатиха Ислям кызы Карникова. Алар барысы да хормәткә лаек кешеләр.
Урамнын ин-ин бәләкәе – 2021 елнын 30 ноябрендә туган Хамид Гафуров. Кvпбалалы гаиләләрне дә бvләкләп vттеләр. Алар - очәр бала тәрбиялəп vстерvче Линар Халим улы белән Алсу Камиль кызы Гафуровлар, Дамир белән Галия Богдановлар.
Бvген дулкынландырган темалар да аталды. Ул - безнен аяз кvк йозебезне Боек Ватан сугышында батырларча сак-лаган якташлар. Аларны олы хормәт белән искә алгач,

хәзерге кондә СВОда доброволец буларак хезмәт иткән Радмир Руслан улы Исякаевка унышлар теләнде. Бу 
урамда яшәгән барлык профессия унганнары исемнәре ишетелде. Гомерен педагогикага багышлаган мактаулы укытучы Раилә Исмаил кызы Ибрагимова исеме хөрмәтләп аталды.

Бәйрәмдә конкурслар оештырылган иде. Барлык бу урамда яшәп эчтәлекле һәм зәвыктыргыч кvргәзмәләр оештыручыларга рәхмәт әйтәсе килә: кемне кайсы конкурста беренче дип әйтергә дә бик авыр булды. Конкурс булгач берничәсен әйтергә туры килә, чонки алар – беренчеләр. «Унган пекарь» Алсу Камиль кызы Гафурова, «Чәчәкләр патшасы» Венера Аббяс кызы Исякаева, ин зур яшелчә vстерvче Алсу Камиль кызы Хайрова, гирьне 45 тапкыр кvтәрvче Линар Халим улы Гафуров. Урам халкы тәмле плов һәм шурпа пешерvчеләргә аерым рәхмәтләрен белдерәләр.
Бәйрәм концертсыз булмый. Кvпторле матур чыгышлар арасында «Умырзаая» солисты Альбина Воробьеванын жырлары халыкнын кvнеленә хуш килде. Исен китәрлек: Энергетиклар урамынын һәрбер яшәvчесе бәйрәмнен актив катнашучысы булды. Чара бик матур vтте. Киләсе бәйрәм 16 сентябрьдә Октябрьская урамында vтәчәк.

**Наилә НАСЫРОВА**